

ISSN 0868-4545



Салават күпере



Аркаң акка буялган!

1 апрель — Көлке көне, Алдау көне. Шаян кешеләр ошбу көнне бер-берсен алдарга тырыша.

— Аркаң акка буялган! — диләр.

— Чалбарыңның тез башы ертылган! — диләр.

— Кибеттә сөйләшә торган балык саталар! Шунда барышым, — диләр...

Тагын әллә ниләр дип алдыйлар.

Кемдер алдый, кемдер алдана. Алдаганнарга карап, хихылдап, хахылдап, кеткелдәп, эчләрен тотып көләләр.

1 апрель көнне син дә кемне дә булса алдарга тырышасыңдыр әле.

Йә, бу юлы кемне алдадың? Әллә алдандыңмы?

Гали, Вәли, Габдулла
Күлдә балык каптыра.
Кемгә эләккән алтын балык?—
Тора алар аптырап...



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

© "Салават күпере", 1999 ел



— Хуҗам! Еракта-еракта сине һәм бер куянны күрәм... Куян сине куа! Җәтрәк өйгә сыптырыйк мәллә?!..

Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Әз-мәз тарих

Апрель җүләрләре


1 апрельдә «алдап көлдерү» хәзер бик күп илләрдә шаяру төсе алган матур бер гадәткә әйләнде.

1860 елның 1 апрелендә Лондонда бик зур «шаяру» була. Әлеге көнне йөзләгән кеше «Тауэрда ак арысланнарны юындыру тантасы»на махсус чакырулар ала. «Апрель җүләрләре» Тауэр капкасы янында иртәдән кичкә кадәр «тантана» башланганын көтәләр. Ниһаять, башларына барып җитә: шаярткannar икән...

Франциядә 1 апрель көнен «Апрель балыгы» дип атап йөртәләр. Бәлки бу көнне Кояш Балык йолдызлыгына туры килгәнгә шулай диләрдер. Ә бәлкем бүтән сәбәбе бардыр. 1564 елда Карл Тугызынчы Яңа елны гадәттәгечә 1 апрельдән дип түгел, ә 1 январьдан башларга дигән указ чыгара. Корольнең указына «буйсынмаган» кешеләр «искечә» яшәүләрен дәвам итәләр: 1 апрельдә дус-ишләренә котлау открыткалары җибәрәләр. Әлбәттә, тора-бара бу шаярту дип кабул ителә.

Россиядә ошбу бәйрәм күбрәк шәһәрләрдә, анда да әдәбият әһелләре арасында үтә торган була.


Ишегалдындагы
Иң көчле кошчыкны тап.
Бу ишегалдына бер урман җәнлеге ялгыш эләккән. Шуны тап әле.
Бәрән ничә балык ашый?
Бу рәсемдәге 19 чәчәк тап.
Шахмат уенында кем җиңә?


Тамаша
Иң авыр бөҗәкне тап.
Бу рәсемдә нинди буталчыклар бар?
Рәсемдә ничә мәче баласы бар?
КИЯ!
Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Әлдәрләргә-табышмак

Агачта үсә ул,
Өлгерми өзмә лә.
Бар минем күздә дә.

(Алма)



Түтәлдә ята арып.
Куя күземне ябып.

(Кабак)



Күз җиткәч өзелә
Агачтан, куактан.
Өзелми колактан.

(Яфрак)



Һәр кулда - ул бишәр.
Биш дип кушсаң әгәр,
Тәмле аш та пешәр.

(Бармак. Бишбармак)



Кешедә — егерме.
Әйтегез, кем белә?
Үсә андый гөл дә.

(Тырнак)



Бик тәмле әйбер ул,
Дәү әни пешерә.
Кайвакыт кешегә
Йоклаганда килә.

(Төш)




Илсөяр Иксанова

Песнәкләр картаямы?

Тәрәзә рамына эленгән җимлектән песнәкләр, чыпчыклар оча-куна көнбагыш ашыйлар. Сәрвиназ аларга карап:

— Песнәкләр картаямы?— дип сорый.

Мондый сорау турында өлкәннәрнең дә уйлануын ул әле белми, әлбәттә.



Дарулар

Сәрвиназ дәү әнисенең дарулар салынган капырка кабын актарып, үзенчә сөйләнеп утыра:

— Монысы — төчкергәч эчә торган дару. Монысы йоклата торган. Монысы уята торган. Монысы җырлата торган дару.



Рәссам Светлана ПРИВИНА

Әхсән Баян

Сәрвиназ хикәяләре

Фехтовальщикович

Сәрвиназның дәү әтисенең әтисе — Фәтхелбаян исемле. Сәрвиназның әтисе Эльбрус — танылган фехтовальщик. Сәрвиназ моны исендә тоткан икән.

Өйгә килгән кунакларның берсе шул хакта Сәрвиназдан сораша:

— Дәү әтиеңнең исеме ничек?

— Дәү әтиемнең исеме — Әкъсән.

— Ә аның әтисенең исеме ничек?

— Әкъсән Фехтовальщикович.





Дәү әтинең көче

Сәрвиназ кемнең көче ни хәтле булуы турында сөйләп торды да, аннары дәү әтисен телгә алды.

— Иң көчлесе — минем дәү эти. Аның көче менә монда хәтле җитә, — дип, кулы белән үзенең муенын сыйпап күрсәтте.

Суга төшкәч, суның тирәнлеген үлчәгән кебек итә, янәсе. Атлап керсәң, муенга җитәсе. Менә нинди көчле аның дәү этисе!

Авырта бит

Уенчык үрдәкне алып, Сәрвиназ алдындагы паласка ташлаган идем, аның кәефе китте.

— Ник ташлыйсың инде, дәү эти, авырта бит инде! — диде.

Бәрелгәч, тән авырта, дигәне шул.

Мин аның сүзен:

— Әйе шул, уйлап җиткермәгәнмен, — дип куәтләгәч, уенчыкны күкрәгенә куеп, сөеп торды.






Алинә Каюмова, 12 яшь.

Чыпчык белән сөйләшү

— Чыпчык башта миңа: «Кәримә, Дәү әниеңә сәлам әйт, авырмасын, сәламәт булсын. Дәү әниеңә җир казырга авыр булса, мин сезгә булышырмын, — диде. Идәнегезне дә юармын,» — диде.


«Мин сезнең җирдәге селәүченнәргә тимим. Алар сезнең җирне йомшартсыннар,» — диде.

«Тәрәзә төпләрегезне дә юармын,» — диде.

«Сез Казанга кайтып киткәч, мин сезгә хат язармын. Хатка марка ябыштырырмын. Маркасына бал сылармын,» — диде.

Без аның белән былтыр танышкан идек инде. Ул чыпчыкның исеме Матуркай бит. Ул минем янга килде дә: «Ничек яшисең, Кәримә?» — дип сорады. Мин: «Җир казыйм,» — дидем. Ул: «Бигрәк әйбәт итеп казыйсың икән. Нәрсәләр утыртасыз?» — диде. Мин: «Бәрәңге, суган, салат, укроп утыртам,» — дидем. Ул: «Бик сәламәт яшәгез, авырмагыз, мин сезгә уңышлар телим,» — диде.

Чыпчык белән сөйләшкәнен Кәримә Дәү әнисенә сөйләгән, ә Дәү әнисе – язучы **Саимә Ибраһимова** *безгә сөйләде.*


Алинә Каюмова, 12 яшь.


Миңа Самара өлкәсенең Камышлы районында булырга һәм Балыклы авылындагы мәктәп укучыларының кулъязмаларын, рәсемнәрен Казанга алып китәргә туры килгән иде. Аларның кайберләре «Сабантуй» газетасында, кайберләре «Салават күпере»ндә чыгар дип өметләнәм. Чөнки аларда укучыларның Балыклыны сүнмәс-сүрелмәс дәрәҗәдә ярата белүләре сурәтләнә һәм сокландыра.

Рөстәм Мингалим.





М.Хәбиров, 8 яшь.



Света Хәсәнова, 13 яшь.



Раил Гафуров, 13 яшь.



Эльнара Закирова, 9 яшь.



Илнур мәзәкләре

Иртәгә чирли

Дәресләр беткәч, Илнур өйләренә китәргә җыена. Ләкин, нәрсәсендер оныткандай, чыгып китә алмыйча, ишек төбендә таптана.

Ниһаять укытучысына эндәшә.

— Апа, мин иртәгә укырга килмим.

— Ни өчен, Илнур?

— Чирлим.

— Бер дә авырганга ошамагансың бит? Бүген көне буе чабып йөрдең.

— Иртәгә чирли башлыйм мин. Безнең авылга кайтасы бар.





Сезнеке кебек инде...

Укытучы Илнурга:

— Илнур, көн саен сумкаң ертыла. Әйберләреңне саклабрак йөрт!

— Сезнеке кебек инде, апа.

— Ничек?

— Кичә автобуста килгәндә пәлтәгезнең сәдәфе өзелгән иде, бүген сумкагызны кискәннәр...



Суга төшкән тавыктай

Укытучы шәһәр транспортында кысылып, соңга калып, тирләп-пешеп класска килеп керә.

Илнур:

— Апа, тизрәк чәчегезне тарагыз, нәкъ минем кебек, суга төшкән тавыктай булгансыз.



Кайсы кулны куясы?

Укытучы:

— Илнур, кайткач әниеңә әйт, билгеләрең белән танышып чыксын да көндәлегеңә кул куйсын.

— Кайсы кулын куйсын, апа, уңынмы, сулынмы?

Җыючысы **Эльмира Шәрифуллина.**

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

1 апрель — шагыйрь Роберт Әхмәтҗан өчен бик тә якын, кадерле көн. Алдашу, матур шаяру һәм Көлке көне булганга гына түгел, әлбәттә. Бу көнне моннан нәкъ 64 ел элек Шагыйрь Абый якты дөньяга килгән. Безне — нәниләрне һәм өлкәннәрне — затлы иҗаты белән сөендерергә дип килгән...

Роберт Әхмәтҗан

Көя кубәләге


(Тел чарлагыч)



Кисә — кача!
Качып кисә-кисә,
Кичә ничә яка тишелгән?
Бүген исә,
Ялтыр-йолтыр, мисле күк җиселе —
Очып чыга
Шкаф ишегеннән,
Оча-сикерә, башы күккә тия —
Керә очып
Ишек тишегеннән!

Тишә — өя,
Кисә — өя Көя, —
Шул сәләткә ия Көя ул.
«Кискән-тишкәннәрен өеп төя, —
Үземнекен кисмим,» — дия Көя...
У, хәйләкәр! —
Ука күлмәк кенә
Кия ул!





Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Рәсемне буяп бетер



Кызларым кызыклары



Тиз генә

Әбисе Ләйсәнне йокларга яткыра. Ләйсән:

— Әби, әби, мин тиз генә йоклыйм да торам, бер сәгать тә бер минуттан уятырсың, яме? — ди.



Румия белән Ләйсән

Кем – кемнән?

Беркөнне әнисе Ләйсәнне эшенә-гимназиягә алып бара. Укытучылар янында ул әнисеннән:

— Әни, әйт әле, мин синнән килеп чыкканмы яки син миннән килеп чыктыңмы! — дип кызыксына.

«Йөрмәсеннәр әле...»

Ләйсән белән Румия әбиләренә ияреп күршеләргә кунакка керәләр. Чыгар алдыннан әбисе: «Кызым, икенче юлы үзегез керегез инде дип әйт,» — дигәч, Ләйсән:

— Йөрмәсеннәр әле, алар болай да безгә күп керәләр, — дип куя.

Бал корты булышкан

Өлкәннәргә ияреп Ләйсән дә базарга чыккан. Карбыз чиратында торганда аны бал корты чаккан. Ләйсән бик каты елаган. Сатучы апа, нәни кызны жәлләп, карбызны бушлай гына биреп җибәргән.

Казаннан Лилия ханым Хәсәнова язып җибәрде.



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





— Килегез, килегез, уйныйбыз...



— Көт. Хәзер килеп җитәм...



— Әлләли! Илләли! Әһ, тәмле!...

ИГЪТИБАР! ИГЪТИБАР! ИГЪТИБАР!

Хөрмәтле әти-әниләр! Кадерле балалар!
«Салават күпере» журналы сезгә янә бер күчтәнәч әзерләде.
Август аенда сез кулыгызга бер **бик матур КИТАП** алачаксыз.
Андый китапны без сезгә елына **дүрт** данә ирештерергә уйлыйбыз. Киләчәктә күбрәк итеп чыгарырга да исәбебез бар. Бу китап өчен өстәп түлисе юк.
Әйтергә кирәк: ул бездән сезгә **бүләк**!
Китап искиткеч язмалардан, мәзәкләрдән, мавыктыргыч хикәятләрдән торачак.

Кыскасы, күчтәнәчебезне көтегез!

Ләбиб Лерон

Мин дә бардым

Алдавыч әкият


Женем сөйми бутап, алдап сөйләүчеләрне! Мин, мәсәлән, билләһи-валлаһи, чын-чын-чын әйтәм, һич алдамыйм, бер ни бутамыйм — гел дөресен генә сөйлим...

Беркөнне иртәгә иртән торып, кайттым-киттем балык тотарга. Уң кулымда — тәртә чаклы, каләм хәтле озын таякчык, якорьдай кармак, сул кулымда — мичкәдән аз гына зуррак чиләк, чиләктә утыз бер ярым балык, унҗиде бака, егерме өч селәү, туксан тугыз борчак...


Килеп җиттем күл буена, кармакка бер балыкны эләктердем дә ташладым суга. Утырам көтеп, чиртми дә чиртми балык. Җыелды халык, җыелды халык...

Менә бер мәлне калкавыч төпкә китте. Тартам, тартам — чыгарып булмый балыкны, ярдәмгә чакырдым халыкны. Тартабыз, тартабыз... Тарта торгач, кармак сабы шартлап сынды. Мәгәр, балыгы зу-у-ур иде — һич алдамыйм, чәнти бармактай юан иде, энәдәй озын иде. Мин аптырап тормадым — күлгә сикердем. Айкала-чайкала торгач, кул белән эләктердем теге балыкны. Алып чыктым яр буена. Балык дигәнем иске итек булып чыкты. Ачудан утыз ярым балыгы (берсен суга салдым бит инде, беләсез), унҗиде бакасы, егерме өч селәүе, туксан тугыз борчагы булган чиләкне суга томырдым да кайтып киттем өйгә.

Кичә иртән торгач, тагын балыкка барам. Син дә минем белән барасыңмы?



Балыкка



Чәнти бармак мишәйт итә

Авыл мәктәпләренең берсендә, башлангыч сыйныфта дәрес бара. Зәйнәп апа балаларны хәрефләр язарга өйрәтә. Илгизәр җәфалана гына бит яза алмыйча. Тирләп пеште, карага буялып бетте үзе тагын. Инде укытучы да авыр сулап, аптырый калып сорап куйды:

— Нишләп соң яза алмыйсың син, үскәнем?..



Илгизәр исә еламсырап:

— Апа, язар идем дә, чәнти бармак мишәйт итә шул, — диеп мышкылдап алды.

Люция Сәйфетдинова.

Зоопаркта



Кызым телевизордан «Хайваннар дөньясында» дигән тапшыруны бик кызыксынып карый.

— Алай җәнлекләрне бик яраткач, иртәгә зоопаркка барырбыз, төрле хайваннар, кошлар карарбыз.

Моңа кызым бик сөенде. Шулай да бераз уйланып торгач, ул:

— Шүрәле бармы соң анда? — дип сорады.

Зоопаркта читлек янына килгәндә аю суда йөзеп йөри иде. Аның судан чыкканын карап торды да:

— Аюның сөлгесе юк бит. Хәзер нәрсәгә сөртенә инде ул? — диде, офтанып.

Мин аюларның салкын кышны кар астында йоклап үткәрүләре турында сөйләдем.

— Ә яз җиткәнен белми калса? Әйдә будильник алып бирик, — диде.

Ренат Галявин.



Илдар Юзеев


Самат хат яза

Исәнме, Капчык бабай?
Сиңа хат яза Самат исемле малай.
Хәзер ул көйсезләнә, акыра.
Әти: «Алып китсен!» дип сине чакыра.
Капчык бабай,
Мин инде елап туйдым бит,
Синең капчыгыңа сыймыйм бит.
Мин хәзер чиста да, тәти дә,
Шулай ди әни дә, әти дә.
Мин озак түзәлмәм,
Тагын еларммын, акырырмын,
«Алып кит!» дип, сине үзем чакырырмын.
Хуш, Капчык бабай!
Бу хатны язды Самат —
Әлегә тәти малай.



Каз бәбкәсе

Каз — әнкәсе.
Аз бәбкәсе.
Саклана күр,
Каз бәбкәсе!



Мөгезе булса да...

Юкка гына
Газиз, куркып,
Табанын ялтырата.
Үгез түгел ич,
сыер ул,
Сиңа сөт алып кайта!



Рәссам Светлана ЯРКОВА



Шуян, Муян һәм Зуян —
Бик сәләтле өч куян.
Өчесе дә музыкант.

Рәсемнәргә кара да
Унҗиде аерма тап!



Рәссам Илдар НӘФИЕВ

Кәкре каенны терәткән

Татар халык әкияте

Борынгы заманда бер алдакчы кеше бар икән, теләсә кемне алдый ала икән. Үзен бик акыллыга санап йөргән тагын бер кеше бар икән, шул кеше әйтә икән:

— Мин шул Алдарга очрасам, аңа һич тә алдатмас идем, — ди икән.

Бервакыт бу кеше юл буйлап барганда күрә, әлеге Алдар бер кәкре каенны терәп тора, имеш. Бу аның янына барып әйткән:

— Я, дус, сине алдарга бик оста дип әйтәләр, мине дә алдый алырсыңмы икән, я, алдап кара әле, — дигән. Алдар әйткән:

— Нигә сине алдый алмам икән? Бик тиз алдар иде дә янымда алдар капчыгым юк шул, өйдә калды, — дигән. Бу кеше Алдарга әйткән:

— Бар, өеңнән капчыгыңны алып кил, мин монда көтеп торырмын, — дигән. Алдар аңа әйткән:

— Өйгә бик кайтыр идем дә, менә бу каен аварга тора, китәргә ярамый бит, — дигән. Бу кеше, бик үрсәләнеп:

— Барсана, капчыгыңны китерсәнә, син килгәнче каенны үзем терәп торырмын, — дип, кәкре каенны терәп калган.

Алдар шул китүдән киткән ди, бу кеше әле дә булса кәкре каенны терәп тора ди.



Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ



Салават күпере

4(110) — 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛУМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 1 битендә
Илдар НӘФИЕВ рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 13.4.99 ел.
Басарга кул куелды 13.4.99 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 16978 данә. Заказ 3-159.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953



— Чәчәк-бизәкләр янында
Мин үзем Чәчәк-Бизәк!..



— Күренмәс парашют белән
Мин күктән төшеп киләм...

— Бизәндем дә утырдым
Үрмәле кәнәфигә...







— Мәчем белән икәүләп
Сурәткә төшик әле...



— Идәндә мүкәләдем,
Диванга үрмәләдем...

— Бүре чыкса, дип, юлыма,
Таяк алдым кулыма...

